РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Менделеевский муниципальный район
Совет Мунайкинского сельского поселения

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге Советы

---

РЕШЕНИЕ

КАРАР

04.04.2025 ел

№ 169

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2024 елның 5 июнендәге 135 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2024 елның 5 июнендәге 135 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советының 2025 елның 22 гыйнварендагы 160 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 4 пунктын үзгәртергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.4. торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексы инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак-коммуналь комплексының торак фондына һәм (яисә) торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән, әлеге абзацта күрсәтелгән эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан җир кишәрлекләреннән тыш) 0,3%;»;

1.2. 2 статьяның 5 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы «Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек оешмаларын үз ихтыяҗлары өчен алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә, әлеге абзацта күрсәтелгән кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан җир кишәрлекләреннән тыш;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru  һәм Менделеевск муниципаль

районының рәсми сайтында «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советы башлыгы Р.М.Кириллов